ШИМБӘ
3 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 27 (5827)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, тенге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

РӘХМӘТ БЕЛДЕРУ

Минем алтмыш еллыгым уңае белән котлаулар һәм яхшы теләкләр җибәргән барлык оешмаларга, җәмгыятьләргә, группаларга, учреждениеләргә, кешеләргә чын күңелдән рәхмәт белдерәм. СТАЛИН.

ГЕРОЙЛАРГА ДАН!

Кичә Ватаныбызның башкаласы, Кремль йолдызлары нурларына чумган Москва батыр седовчыларны—ялкынлы патриотларны каршы алды. Бөтен ил, бөтен совет халкы чиксез зур шатлык һәм горурлык кичерә, Ватаныбызның данын арттыручы, Совет иленең куәтле, көчле икәнлеген, аның бер кайчан да җиңелмәслеген тагын да бер тапкыр бөтен дөньяга күрсәтүче патриотлар—седовчылар хөрмәтенә, „И. Сталин“ бозваткычының экипажы хөрмәтенә зур тантана, очрашу бәйрәме ясыйлар.

Үзәк Арктика бушлыкларында, көчле бураннарда, котыпның мәңгелек салкынлыгында, шашкынулы бозлар арасында 812 көн! Бу Арктика стихияләренә каршы совет халкы семьясеннән 15 батырның героик көрәш көннәре. Бу, партиябезнең, хөкүмәтебезнең һәм иптәш Сталинның заданиесен үтәү өчен, совет фәнен, Арктиканы өйрәнү фәнен тагын да югары баскычка күтәрү өчен, Ватаныбызның данын тагын да арттыру өчен үз-үзенне аямыйча көрәшү көннәре иде. Большевиклар ала алмаган крепостьлар юк! Ватанга, бөек большевиклар партиясенә һәм бөтен дөнья хезмәт ияләренең сөекле юлбашчысы, котыпчыларның якын дусты даһи Сталинга чиксез бирелгән седовчылар җиңеп чыктылар. Партияле һәм партиясез большевиклардан торган 15 кешелек коллектив кешелек дөньясы тарихына тагын да бер зур җиңүне язып куйды.

Седовчыларның әкияттәгечә искиткеч батырлыклары—ул совет халкының уртак батырлыгы, ул совет халкына тулысынча хас булган геройлык. Безнең илебезнең һәрбер хезмәт иясе партиянең, хөкүмәтнең теләсә нинди заданиесен, теләсә нинди шартларда да үтәргә һәр вакыт хәзер тора. Зур уңышларның, седовчылар күрсәткән кебек мондый кыюлыкларның бары тик безнең илдә генә, социалистик илдә генә булуы мөмкин. Моның өчен безнең илебездә барлык шартлар бар: материал - техник база тудырылган, барсыннан да элек, һәм иң беренчесе, кешеләр турында гаять зур кайгыртучанлык күрсәтү тәэмин ителгән. Седовчылар үзәк Арктиканың бозлары арасында яшәгәндә, иҗад иткәндә, алар үзләрен бер вакытта да аерылып калган итеп хис итмәделәр, алар һәр вакытта да Зур Җир белән элемтәдә, совет халкы белән бергә булдылар.

Ватаныбызның радио дулкыннары алып барган һәрбер хәбәр, юлбашчының һәм Совет хөкүмәте башлыгының котлап җибәргән телеграммалары батырлар коллективына көч, дәрт кертте. Мурман өлкәсе хезмәт ияләре 15 батырның барсын да җирле Советларга депутат итеп сайладылар. Бу, аларны сайлаучыларның гына түгел, бәлки илебезнең барлык хезмәт ияләренең батырларга карата зур ихтирамнары, мәхәббәтләре иде. Бу, депутат дигән мактаулы исемне дә седовчыларның намус белән аклаячакларына зур ышаныч күрсәтү иде.

„Безнең хәрәкәт тәмам булды. Аның төп йомгагы шуннан гыйбарәт ки, без совет кешесенең, большевикның, социалистик Ватан патриотының нәрсәләргә сәләтле икәнлеген бөтен дөньяга тагын бер тапкыр күрсәттек.

Безне большевистик партиябез тарафыннан җитәкләнүче Ватаныбыз алып барды, үзенең кайгыртучанлык күрсәтүе белән безне иптәш Сталин рухландырды. Без тыныч булдык, чөнки иптәш Сталин совет кешеләре турында бер кайчан да онытмый“. „Седов“ бозваткычы капитаны иптәш Бадигинның бу сүзләрендә совет кешесенең гүзәл образлары гәүдәләнгән, социалистик Ватанда кешенең кыйммәтле капитал икәнлеге ачык чагылган.

Үлемгә дучар ителгән, череп бара торган капитализм дөньясына капма-каршы буларак, безнең илебез экономика һәм идея-политик тормыш өлкәсендә көннән-көн яңа, зур уңышларга ирешә, социалистик культура, фән чәчәк ата Совет халкы Төньяк Котыпның салкын бушлыкларындагы серләрне ачканда, аларны кешелек дөньясы байлыгы итү өчен аяусыз көрәш алып барганда, Англия, Франция капиталистлары үз илләрендәге хезмәт ияләрен актык хокукларыннан да мәхрум итәләр, кешелекнең алдынгы фикер ияләренең әсәрләрен, кешелек дөньясе хезинәләрен юкка чыгаралар, хезмәт ияләренең яраткан газеталарын ябалар, туганның туганы белән сөйләшүен дә тыюга кадәр барып җиттеләр. Бөек совет халкы һәм аның куәтле, җиңелмәслек Кызыл Армиясе фин халкын маннергейм—таннер бандаларыннан азат итү өчен, дөньяда тынычлык урнаштыру өчен героик көрәш алып барган вакытта, Англия һәм Франция капиталистлары үз илләрендәге хезмәт ияләрен сугыш утына ташлыйлар, төрмәләргә тутыралар, каторгаларга озаталар. Империалистик сугышка һич тә бәйләнеше булмаган сәүдә пароходларын суга батырып, диңгез бандитлыгы белән шөгыльләнәләр.

Большевиклар партиясе җитәкчелегендәге совет халкының бүгенгесе матур, ә иртәгесе тагын да гүзәлрәк. Совет халкы моңа нык ышанган. Шунлыктан, ул бары тик бер теләк белән: седовчылар кебек үк кыю булырга, илне баету, ныгыту өчен, коммунизмның тантанасы өчен көрәшнең алдынгы сафларында булырга дигән теләк белән тулган. Нак менә шул теләк нигезендә безнең илебездә геройлар армиясе сафлары көннән-көн киңәя бара.

Күп меңле котыпчылар семьясенең кечкенә бер коллективы булган седовчыларны Мурман хезмәт ияләре иң беренче булып каршы алдылар. Ленин шәһәре хезмәт ияләре дә батырлар белән күрешү тантанасын үткәрделәр. Кичә илебезнең йөрәге—Москва хезмәт ияләре һәм алар белән берлектә бөтен илебез геройлар белән күрештеләр, аларны үзләренең җылы кочакларына алдылар.

— Хуш килдегез, седовчылар! Сезгә, седовчыларга, „И. Сталин“ экипажы членнарына, орденлы Татарстаннан ялкынлы сәлам!

Художник Г. Поляков рәсме.

МОСКВА ГЕРОЙЛАРНЫ КАРШЫЛЫЙ

Легендар „Георгий Седов“ бозваткычының моряклары 2 нче февральдә Москвага килеп җитәләр. Башкала совет халкының данлыклы улларын лаеклы рәвештә каршыларга хәзерләнә.

Үзәк проездлар бәйрәмчә бизәләләр. Төньяк Диңгез Юлы Баш Идарәсенең бинасы матур итеп бизәлә. Бирегә зур паннолар куела. Аларның берсендә Сталин һәм Молотов иптәшләрнең һәм седовчы геройларның портретлары булачак. Икенче панно „И. Сталин“ һәм „Г. Седов“ бозваткычларының очрашуын гәүдәләндерәчәк.

Чиксез илебезнең барлык почмакларыннан котлау телеграммалары килә. Батыр седовчыларны, Ватанга кайтулары уңае белән, Москва предприятиеләренең һәм учреждениеләренең коллективлары, орденлы Башкыртстан республикасы яшьләре, Адыгея автономияле өлкәсенең хезмәт ияләре һәм башка бик күпләр котлыйлар.

Москва хезмәт ияләре седовчы геройларга күп санда бүләкләр хәзерлиләр.

Сталин исмендәге автозаводның күп меңле коллективы седовчылар белән очрашуны түземсезлек белән көтә. Котыпчы геройларны каршылау өчен автозаводчылар „ЗИС—102“ маркалы махсус машина хәзерләделәр. Барлык цехларда седовчылар турында көн саен кычкырып укулар һәм беседалар үткәрелә. Иптәш К. С. Бадигинның завод коллективына җибәргән телеграммасын автозавод эшчеләре һәм хезмәткәрләре гаять зур шатлык белән каршыладылар. Телеграммада болай диелә:

„Туган җирдә булуыбызның беренче көннәре шатлык һәм бәхет белән тула. Поезд безне үзебезнең бөек Сталиныбыз яши һәм эшли торган Москвага—Кызыл башкалага алып бара.

Рәхимсез Арктика бозлары арасында үзебезнең кыен юлыбызны без йөрәкләребездә Сталин исме белән башладык. Бозлар арасындагы хәрәкәтебезнең барлык көннәрендә дә бу исем безнең өчен сүнмәс яктылык булды. Бозларның кысуы да, рәхимсез давыл да, көчле салкыннар да безнең теләкне какшата алмадылар. Бөтен совет халкының һәм юлбашчыбыз, туганыбыз иптәш Сталинның булышлык күрсәтүе, максатның ачык булуы, седовчыларның бөтен коллективының үз-үзен аямыйча бердәм рәвештә эш алып баруы җиңүне тәэмин иттеләр, фәнни эшләрне уңышлы төгәлләүне, экипажның һәм карабның саклануын тәэмин иттеләр.

Үзебезнең Москвабызга кайтарак, Сталин исмендәге автозаводның стахановчыларын, производство алдынгыларын, эшчеләрнең һәм хәзмәткәрләрнең күп меңле бөтен коллективын бөтен экипаж исменнән кайнар рәвештә котлыйм һәм аларны яңа казанышлар өчен көрәшкә чакырам“. (ТАСС).

„Г. Седов“ бозваткычының героик хәрәкәтендә катнашучыларның иптәш А. Жданов белән очрашуы

ЛЕНИНГРАД, 1 февраль. (ТАСС). „Г. Седов“ бозваткычының героик хәрәкәтендә катнашучылар бүген Смольныйда ВКП(б) ның Ленинград Өлкә Комитеты һәм Шәһәр Комитеты секретаре иптәш А. Жданов белән очраштылар. Седовчылар, чын күңелдән алып барылган җылы беседада иптәш Ждановка үзләренең, партия Үзәк Комитеты һәм иптәш Сталинның үзенең кайгыртучанлык күрсәтүләре белән рухланган хәлдә, партия һәм хөкүмәт заданиесен ничек үтәгәнлекләре турында сөйләделәр.

Кич белән, седовчылар Москвага китәр алдыннан, Ленинградның партия, совет һәм хуҗалык активы белән батыр котыпчыларның иптәшләрчә очрашуы булды.

(ТАСС).

ХАЛЫК ЭПОПЕЯСЕ

Арктиканы кыю тикшеренүчеләр—данлыклы „Седов“ карабы моряклары бүген Советлар иленең Кремльдәге рубин йолдызлар белән балкыган башкаласына кайталар.

Үзләрендә совет кешеләренең гүзәл сыйфатларын гәүдәләндерүче батыр седовчы-геройларга бөтен куәтле халкыбыз чын күңелдән кул чаба.

Геройлык халкыбызның көнкүрешенә нык керде. Ул промышленность, транспорт һәм социалистик кыр стахановчыларының хезмәт батырлыкларында, Арктиканы буйсындыручыларның батырлыкларында, сугыш уты кабызучы кабахәт ак фин бандаларына каршы безнең Кызыл Армиянең һәм Кызыл Флотның җиңүчән көрәш алып баручы данлыклы сугышчыларының героик эшләрендә чагыла.

Геройлар халкы, иҗад итүчеләр халкы—совет халкы Арктика баһадирларының Москвага кайтулары көнен тантаналы төстә билгеләп үтә. Бу—халыкның яңа эпопеясенең, үзенең даны гасырларга җәеләчәк эпопеянең төгәлләнүе.

Төньяк Боз океаны сәхраларында седовчылар тарафыннан зур һәм кирәкле эшне башкарганда күрсәтелгән чиксез батырлык безгә, Арктика бураннары һәм салкыннары белән йөзгә-йөз очрашкан котып очучыларына бигрәк тә аңлаешлы.

Арктиканы буйсындыру эшендә ел саен яңадан-яңа уңышларга ирешелә. Бу рәхимсез өлкәнең совет кешеләре тарафыннан тулысынча үзләштереләчәк көне ерак түгел. Төньяк диңгез юлын нормаль төстә эшләүче су магистрале итү турында партиябезнең XVIII нче съезды директивалары үтәләчәк көн ерак түгел.

М. В. Водопьянов.
Советлар Союзы Герое.

КҮПТӘН ТҮГЕЛ КОНФЛИКТ БУЛГАН РАЙОНДА МОНГОЛИЯ ХАЛЫК РЕСПУБЛИКАСЫ БЕЛӘН МАНЧЖОУ-ГО АРАСЫНДА ЧИКНЕ ТӨГӘЛ БИЛГЕЛӘҮ БУЕНЧА КАТНАШ КОМИССИЯНЕҢ БЕРГӘЛӘП БЕЛДЕРҮЕ

Комиссиянең 1939 нчы ел 7 нче декабрьдән алып 25 нче декабрьгә кадәр Чита шәһәрендә һәм 1940 нчы елның 7 нче январеннан алып 30 нчы январена кадәр Харбин шәһәрендә булган 16 утырышында, чикне төгәл билгеләү мәсьәләсе буенчаСовет—Монголия һәм Япония—Манчжоу-Го делегацияләренең карашлары тулысынча капма-каршы икәнлеге беленде.

Шунлыктан, тарафларның карашлары тулысынча капма-каршы булу нәтиҗәсендә, агымдагы елның 30 нчы январенда, Япония хөкүмәте уполномоченные Кубота әфәнде председательлегендә үткәрелгән соңгы утырышта комиссия үзенең эшен туктатырга карар бирде.

ТАСС ИСКӘРМӘСЕ

Совет—Монголия һәм Япония—Манчжоу-Го делегацияләре вәкилләреннән торган катнаш комиссия, 1939 нчы елның җәендә Совет—Япония арасында булган мәгълүм конфликт районында Монголия Халык Республикасы белән Манчжоу-Го арасындагы төгәл чикне тиешле авторитетлы рәсми документлар нигезендә билгеләүне максат итеп куйган иде. Бу документларны карауга катнаш комиссиянең 1939 нчы елның декабрендә һәм шушы елның январенда Читада һәм Харбинда үткәрелгән утырышлары багышланган иде. Чикнең күптәннән үк яшәп килгән һәм элек бер кем тарафыннан да бәхәс ителмәгән линиясен яңадан карауны нигезләү максаты белән Япония—Манчжоу-Го ягы тарафыннан кертелгән документларның авторитетлы рәсми документларга охшашлары да булмаганлыктан, Совет—Монголия делегациясе бу документларны чикне төгәл билгеләү өчен нигез итеп танудан баш тартты. Совет—Монголия ягы тарафыннан кертелгән авторитетлы рәсми документлардан Япония—Манчжоу-Го ягы баш тартканлыктан, катнаш комиссия, килешенгән гомуми карар кабул итмичә, таралды.

МОСКВА, КРЕМЛЬ

Иптәш Сталинга

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Без, орденлы Татарстанның социалистик авыл хуҗалыгы алдынгылары, республика киңәшмәсенә җыелып, 1940 нчы елга карата булган бурычларыбызны тикшергән хәлдә, үзебезнең мәхәббәт һәм рәхмәт сүзебезне Сезгә, кадерле атабызга һәм колхоз крестьяннәренең бөек дустына багышлыйбыз.

Героик Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә, Сезнең көндәлек ярдәмегез һәм кайгыртучанлык күрсәтүегез белән, социалистик авыл хуҗалыгы бөтен дөнья күләмендә тарихи җиңүләрне яулап алды. Бу җиңүләр 1939 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә бөтен дөньяга ачык рәвештә күрсәтелделәр. Безнең уңышларыбыз—алар колхозларның һәм совхозларның чәчәк атуы турында Сезнең игтибарыгыз һәм аталарча кайгыртучанлык күрсәтүегез нәтиҗәсе. Авыл хуҗалыгы мәсьәләләре буенча Сезнең бөек һәм зирәк киңәшләрегез, күрсәтмәләрегез, сөекле Иосиф Виссарионович, безне үзебезнең бөек Ватаныбызның даны өчен, колхоз строеның даны өчен яңа җиңүләргә коралландыралар һәм рухландыралар.

Социалистик игенчелекнең һәм терлекчелекнең резервлары чиксез. Колхоз строе, куәтле машина техникасы, алдынгы агрономия фәнен авыл хуҗалыгына кертү—менә болар, электә күрелмәгән иген уңышлары алуны мөмкин итеп куялар. Безнең республиканың алдынгы колхозлары, бөтен илнең алдынгы колхозлары шикелле үк, моны үзләренең тәҗрибәләрендә бик яхшы итеп расладылар, күп кенә еллар буе алар югары иген уңышы алып киләләр.

Бу уңышларны арттыру өчен, алдынгыларның тәҗрибәсен Татарстандагы барлык колхозларның, совхозларның һәм МТС ларның уртак тәҗрибәсе итү өчен, без үзебезнең бөтен көчләребезне куярбыз. Йөзпотчыларның Бөтенсоюз социалистик ярышына кушылган хәлдә, без халыкның бу гүзәл хәрәкәтендә беренчелек өчен, ел саен 8 миллиард пот ашлык алу турында Сезнең күрсәтүегезне тормышка үткәрү өчен ныклы көрәш алып барачакбыз.

Кадерле Иосиф Виссарионович!

1940 нчы елның 25 нче июнендә Татарстан АССР үзенең XX еллыгын бәйрәм итәчәк. Безнең республиканы оештыру социалистик революциянең бөек даһилары Ленин һәм Сталин исемнәре белән бәйләнгән булуны без аеруча мәхәббәт һәм елылык белән, бөек шатлык һәм горурлык белән билгеләп үтәбез. Сез, безнең туган атабыз һәм остазыбыз, Ленин белән берлектә безнең республиканы барлыкка китерүнең инициаторы булып торасыз. Сезнең бөек җитәкчелегегез астында, Сезнең көндәлек игтибарыгыз һәм аталарча кайгыртучанлык күрсәтүегез белән, Татарстан АССР социалистик төзелешнең барлык өлкәләрендә гаять зур уңышларга ирешә, орденлы алдынгы республикага әйләнде. Сезнең исмегез безне яңа җиңүләргә рухландыра.

Туганыбыз Иосиф Виссарионович, Сезне ышандырабыз: колхозларның һәм совхозларның куәтен армый-талмый ныгытырбыз, Ватаныбызның оборона сәләтен ныгытырбыз, һәрберебез үз участкыларыбызда үзебезнең героик Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенә ярдәм күрсәтербез.

Яшәсен җиңелмәслек большевиклар партиясе!

Яшәсен бөтен дөнья хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы, колхозчы крестьяннәрнең туган атасы һәм иң яхшы дусты иптәш СТАЛИН!

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы карары

Әдәбият буенча Сталин исмендә премияләр булдыру турында

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советының „Сталин исмендә премияләр һәм стипендияләр булдыру турында“ 1939 нчы елның 20 нче декабрендә чыгарган карарына өстәмә итеп, ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы карар бирә:

Сталин исмендә, әдәбият өлкәсендә иң күренекле әсәрләр өчен ел саен бирелә торган һәрберсе 100 әр мең сумлык дүрт премия булдырырга:

Берсе—поэзия буенча,
Берсе—проза буенча,
Берсе—драматургия буенча,
Берсе—әдәби тәнкыйт буенча.

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе В. МОЛОТОВ.

СССР Халык Комиссарлары Советы эшләрен идарә итүче М. ХЛОМОВ.

1 февраль, 1940 ел.
Москва, Кремль.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАЛАРЫ

31 нче январьда фронтта хәрби хәрәкәтләр разведчикларның эзләнүләре белән чикләнде.

Безнең авиация разведка очышлары үткәрде.

***

1 нче февральдә фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация разведка очышлары үткәрде һәм сугыш объектлары буйлап хәрби хәрәкәтләр башкарды, шулар вактында дошманның 3 самолеты бәреп төшерелде.

Бүген, 3 нче февральдә, 18 сәгатьтә Менжинский исмендәге клубта (Карл Маркс урамы)

ПАРТИЯ АКТИВЫНЫҢ ШӘҺӘР КҮЛӘМЕНДӘГЕ ҖЫЕЛЫШЫ БУЛА

Көн тәртибендә: ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы йомгаклары һәм партиянең Казан шәһәр оешмасының чираттагы бурычлары турында (докладчы иптәш Бычков).

Пропускалар ВКП(б) ның Казан шәһәр райкомнарында бирелә.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты.

ВАТАН ҮЗ ГЕРОЙЛАРЫН КОТЛЫЙ

ЯҢА ҖИҢҮ

Сталин юлы белән баручы Ватаныбызга һәрбер ел яңа җиңүләр китерә. Совет кешеләре, кайда гына булсалар да, аларны Ватаныбыз кайда гына җибәрсә дә, үз-үзләрен аямау, батырлык һәм тотнаклылык могҗизалары күрсәтәләр. Седовчыларның батырлыгы—моның ачык дәлиле.

„Седов"ның хәрәкәте совет кешеләре геройлыгының, аларның гүзәл эшенең чиге юклыкны бөтен дөньяга тагын бер кат күрсәтә.

Рядовой совет морякларыннан торган седовчылар коллективы Ватаныбызның байрагын, Ленин—Сталин п ртиясе байрагын күп еллык бозлар һәм котып төне караңгылыгы аркылы намус белән алып барды. Седовчылар Ватаныбыздан ерак иде, ләкин алар үзләрен Ватаннан аерылган дип хис итмәделәр. Ул аларны үзенең аналарча елылыгы белән елытты, бөек Сталин аларны юлда очрый торган барлык киртәләрне җиңәргә рухландырды.

„Седов"ның героик хәрәкәте кешенең әле моннан берничә еллар элек кенә ирешә алмаслык дип саналган үзәк Котып бассейнының чиксез боз сахралары турындагы белемен тагын да киңәйтте. Төньяк котыпны һәм Котып тирәсендәге районны ниндидер ирешә алмаслык нәрсә дип күз алдына китерү хәзер мәңгегә югалды. Совет кешеләре җиңә алмаслык киртәләр юклыкны, алар җиңә алмаслык кыенлыклар юклыкны седовчылар бөтен дөньяга тагын бер кат күрсәттеләр.

М. М. Громов.
Советлар Союзы Герое.

ИСКИТКЕЧ БАТЫРЛЫК

Бүген Советлар иле башкаласы данлыклы седовчыларны мәхәббәт һәм шатлык белән каршы ала.

Котыпчы геройларның искиткеч батырлыгында совет халкының гүзәл сыйфатлары: Ватанга чиксез мәхәббәт, Ленин—Сталин партиясенә чын күңелдән бирелгәнлек, батырлык һәм ныклык чагылды.

Совет котыпчыларының табигаткә каршы героик көрәше, большевикларның Арктиканы үзләштерүләре Сталин эпохасының тарихи вакыйгаләре язмасына данлыклы сәхифә булып керер. Коммунизм төзүчеләр образы, совет кешесе образы геройларыбызны һәм шушы геройларны тәрбияләгән бөек юлбашчыларыбызны мәңгегә истә калдырырлык әсәрләр тудыруга архитекторларны, скульпторларны һәм художникларны рухландыра.

Седовчыларның героик эпопеясен бөтен илебез гаят зур соклану һәм горурлык белән күзәтеп торды. Бүген Кызыл башкала бөтен совет халкы исменнән батыр коллективка әйтә:

— Сез Ватаныбызның ышанычын акладыгыз. Сез бөек Сталинның заданиесен намус белән үтәдегез. Рәхим итегез!

Б. М. Иофан.
Архитектура академигы.

СТАЛИН ТӘРБИЯЛӘП ҮСТЕРГӘН КЕШЕЛӘР

Седовчылар! Бу сүз һәрбер совет патриотына якын булып әверелде. Моннан соң папанинчылар дигән сүз кебек үк бу сүз белән дә рәхимсез табигатне җиңүче һәм совет фәнен кыйммәтле яңалыклар белән баетучы котыпчыларның батырлыгы билгеләнәчәк.

Седовчыларның фәнни материаллары галимне дә, морякны да, очучыны да бер үк дәрәҗәдә борчый торган әһәмиятле сорауларга җавап бирәләр. Седовчылар „Санников җире" барлыгы турындагы легенданы тәмам бетерделәр, һава картасын яхшырттылар, батыр папанинчылар ачкан яңалыкларга өстәмә керттеләр. Седовчыларның материаллары буенча төзелгән яңа магнит карталары котып капитаннарына һәм очучыларга үзләренең карабларын нак билгеләнгән курс буенча ышаныч белән һәм ялгышмыйча алып барырга мөмкинлек бирерләр.

Бозлар арасында хәрәкәт итүнең авырлыклары артта калды. Бүген седовчылар Москвага кайталар. Башкала хезмәт ияләре бөек Сталин тәрбияләп үстергән совет кешеләренең нәрсәләргә сәләтле икәнлекләрен бөтен дөньяга ачык итеп күрсәткән кыю геройларны шатланып алкышлыйлар.

Сталин тәрбияләп үстергән батырларга сәлам!

В. С. Молоков.
Советлар Союзы Герое.

СЕДОВЧЫЛАР ТӘҖРИБӘСЕН—БӨТЕН ДӨНЬЯ ФӘНЕ ХӘЗИНӘСЕНӘ

Батыр седовчыларның фән каршындагы хезмәтләре чыннан да гаять зур. Гидрологлар, метеорологлар, геофизиклар, гидрографлар, астрономнар, океанографлар Арктиканың тикшерелмәгән районнарында совет кешеләре тарафыннан табылган кыйммәтле фәнни материаллар алачаклар. Бу материалларны җентекләп эшләү, аларны туплау—совет фәненең әһәмиятле һәм мактаулы бурычы.

СССР Фәннәр Академиясе хәрәкәтнең йомгаклары турында совет галимнәре алдында доклад ясауны үтенеп седовчыларга мөраҗәгать итте. Бадигин, Буйницкий һәм Трофимов иптәшләр героик экипажның фәнни эшләре турында белдерү ясарга үзләренең хәзер торуларын белдерделәр.

Материктан еракта, рәхимсез салкынлык һәм бозлы җилләр шартларында илебезнең данлыклы 15 патриоты бер генә минутны да юкка әрәм итмәделәр. Алар пароходны хәрәкәттәге фәнни станция итеп әверелдерделәр. Алар кар катлавының үзгәрешләрен, бозларның ярылуын тулысынча язып алдылар. Экипаж агымнарны өзлексез күзәтте, океан төпләрен уннарча тапкыр үлчәде.

„Седов" „Фрам" рекордыннан узды. „Фрам"—85 градус 57 минут төньяк киңлеккә барып җиткән беренче караб. „Седов" исә 86 градус 40 минут төньяк киңлеккә барып җитте. Шулай итеп „Седов" хәрәкәте котып бассейнының аңарчы бер генә караб та барып җитмәгән өлкәсенә барып җитте. Алынган материалларны тирәнтен өйрәнү Арктика режимындагы теоритик яктан гына түгел, бәлки практик яктан да кызыклы булган гидрометеорология үзгәрешләренә төшенергә мөмкинлек бирер. „Седов" ның хәрәкәте вактында алып барылган күзәтүләр безгә үзәк Арктиканың табигатен тирәнрәк аңларга, совет фәне алдына куелган төп бурычны—Төньяк диңгез юлын нормаль төстә эшләүче су юлы итеп әверелдерүдә ярдәм итү бурычын хәл итүгә якынрак килергә мөмкинлек бирерләр.

„Седов"ның уңышы—очраклы хәл түгел. Партиянең һәм хөкүмәтнең кайгыртучанлыгы белән чолгап алынган, илебездәге миллионнарча кешеләрнең игтибары белән рухланган героик моряклар алдынгы совет фәне файдасына армый-талмый һәм үз-үзләрен аямыйча хезмәт иттеләр. Совет галимнәре бүген Советлар Союзының башкаласына кайтучы гүзәл патриотларны бөтен халкыбыз белән берлектә чын күңелдән котлыйлар.

Рәхмәт Сезгә, кадерле иптәшләр! Сез алдынгы фәннең даны өчен, бөек Ватаныбызның даны өчен яхшы эшләдегез.

Е. А. Чудаков.
СССР Фәннәр Академиясенең вице-призеденты.

МИЛЛИОННАРЧА СОВЕТ ПАТРИОТЛАРЫ ӨЧЕН ҮРНӘК

Бүген Кызыл башкала һәм бөтен күп миллионлы совет халкы герой седовчыларны шатланып каршы ала. Аларның үзләренең героик эшләрен уңышлы төгәлләп яңадан туганнары һәм якыннары арасында булуын күреп без чиксез бәхетлебез.

Седовчыларның гүзәл хәрәкәте бөтен дөнья күләмендә фән хәзинәсенең кыйммәтле байлыгы булып, социалистик Ватанга совет кешеләренең чиксез мәхәббәтләренең яңа дәлиле булып тарихка керер. Рәхимсез Арктика шартларында седовчыларның героик тормышы илебезне һаман алга алып баручы совет патриотизмы көченең яңа дәлиле булып хезмәт итә.

Совет патриотизмы, социалистик патриотизм үзендә коммунизм өчен көрәштә тудырылган, большевиклар партиясе тарафыннан тәрбияләнгән яңа кешенең барлык сыйфатларын чагылдыра. Совет халкы Ватан турындагы фикерләре белән, бөек Сталин исме белән яңадан-яңа җиңүләргә ирешә. Седовчыларның кыю батырлыгы — миллионнар өчен, Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән барлык кешеләр өчен үрнәк, чын халык геройлыгы үрнәге. Седовчылар—миллионнарның, Ленин— Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән барлык кешеләрнең лаеклы уллары. Седовчылар—Ватаныбызның лаеклы уллары, бөек Сталин тәрбияләп үстергән лаеклы кешеләр.

В. Хетагурова.
СССР Верховный Советы депутаты.
(ТАСС).

ГЕРОЙЛАР—СЕДОВЧЫЛАР ЛЕНИН ШӘҺӘРЕНДӘ

Ленинград хезмәт ияләре данлыклы геройларның—седовчыларның кайтуын түземсезлек белән көттеләр. Радиорепродукторлар иртә белән үк инде кадерле кунакларны алып килүче поездның Ленинградка якынлашуы турындагы хәбәрне тараттылар.

9 сәгать 40 минутта перронда почетлы караул төзелә. Поезд акрын гына дебаркадерга якынлаша. Седовчылар вагоннан чыгалар, аларны котлау тавышлары һәм „ура" кычкырулар белән каршы алалар.

Почетлы караулның начальнигы Папанин һәм Бадигин иптәшләргә рапорт бирә.

Седовчылар вокзал янында урнаштырылган трибунага юнәләләр.

Хезмәт ияләре депутатларының Ленинград шәһәр советы башкарма комитеты председателе иптәш Попков митингны ача.

Аннары микрофон янына Орджоникидзе исемендәге заводның атаклы караб төзүчесе иптәш Яцынов килә. Ул болай ди:

— Ленин шәһәренең хезмәт ияләре бу шатлыклы көндә, Арктика флотының флагманы „Иосиф Сталин"ның Ленинградта төзелгән булуы белән аеруча горурланалар, ул легендар бозваткыч „Седов" ны бозлар тоткынлыгыннан азат итте һәм героик экипажны Зур Җиргә алып кайтты.

Кадерле седовчылар, сезнең геройлыгыгыз Ленин шәһәре хезмәт ияләрен производствоның яңа җиңүләре өчен көрәшкә рухландыра. Без хәзер икенче куәтле линейный бозваткыч—„Вячеслав Молотов" бозваткычы төзибез һәм аны иң кыска срокларда төзеп бетерүгә ирешербез. Безнең зур диңгез һәм океан флотының караблары дөньяда иң яхшы караблар булырлар.

Трибунада—лейтенант Кубатко. Ул фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында хәрәкәт итүче Кызыл Армиянең сугышчылары һәм командирлары исменнән, седовчыларга кызыл армеецларча кайнар сәлам тапшыра.

Сүз „Г. Седов" бозваткычы капитаны К. С. Бадигинга бирелә. Котлаудан соң ул болай диде:

— Бозлар арасында һәм Котып төне караңгылыгында безне Арктика флотының иң яхшы карабы каршы алды. Бу карабның рейсына иптәш Папанин җитәкчелек итте. Котып артындагы Баренцбург шәһәрендә, Мурманскида, данлыклы Ленин шәһәренә кадәр булган бөтен юлда, барлык станцияләрдә һәм полустанкларда Совет патриотлары безне дуслык һәм мәхәббәт сүзләре белән каршы алдылар. Бу сүзләрдә без совет кешеләренең тирән теләктәшлеге һәм ныклыгы хисен күрдек.

Иптәш Бадигин үзенең речен:

— Яшәсен безнең туган атабыз, остазыбыз, дусыбыз иптәш Сталин!—дигән сүзләр белән тәмам итә.

Микрофон янында — Советлар Союзы Герое И. Д. Папанин. Ул болай диде:

— Илебезнең хезмәт ияләре үзләренең данлыклы улларын гаять зур мәхәббәт һәм шатлык белән каршы алалар. Седовчылар—Совет халкының батырлыгын, геройлыгын чагылдыралар. Үз Ватаннарына карата мәхәббәт белән рухланган, большевистик партиягә, үзенең юлбашчысы иптәш Сталинга чын күңелдән бирелгән совет кешеләре Ватан даны өчен бик яхшы батырлыклар эшлиләр.

Без Ватаныбызны яратабыз һәм аның чәчәк атуы өчен бөтен көчебезне бирәбез. Безнең бехтебезне, безнең бәхетле тормышыбызны бер кайчан һәм бер кем тартып ала алмас.

Илебезнең тарихы данлыклы батырлыклар белән тулы. Башкача булырга да мөмкин түгел. Капитализм изүеннән азат ителгән халык, социализм төзүче халык—ул, героик халык. Большевиклар партиясе һәм халыкларның юлбашчысы иптәш Сталин аны җиңүләрдән-җиңүләргә алып баралар.

Иптәш Сталин хөрмәтенә көчле алкышлар яңгырый. Пролетар гимн тавышлары мәйданны каплап ала.

Митинг тәмам була. Седовчылар машиналарга юнәләләр. Проспектта аларны ун меңнәрчә ленинградлылар көтәләр. Халык Арктиканы үзләштерү өчен көрәш тарихына бик яхшы яңа сәхифәне язган үз геройларын чын күңелдән котлый.

Талантлы пролетар полководец

(М. В. Фрунзенең тууына 55 ел тулуга карата)

М. В. Фрунзе (1885—1925).

1885 нче елның 2 нче февралендә (иске стиль белән 21 нче январьда) заманыбызның гүзәл кешеләреннән берсе, ялкынлы революционер-большевик һәм күренекле пролетар полководец Михаил Васильевич Фрунзе туды. Ул Семиречье өлкәсенең Пешпәк шәһәрендә (хәзерге Фрунзе шәһәре) туды. Аның атасы—элекке крепостной крестьян—фельдшер иде.

1904 нче елны Фрунзе Верный шәһәрендә гимназияне тәмам итә һәм Петербургда Политехника институтына керә.

Гимназиядә вактында ук Михаил Фрунзе революцион идеяләр белән кызыксына, түгәрәкләрдә эшли. 1904 нче елны, политехника институтының 1 нче курсында вакытта ул социал-демократлар оешмасына керә һәм аның большевистик өлешенә кушылып, үзенең соңгы көннәренә кадәр большевизмга турылыклы булып кала.

Иптәш Фрунзе бөтен тормышын революцион эшкә багышлый.

1905 нче елны, беренче рус революциясе вактында, Михаил Фрунзе „студентлар чуалышларында" катнашкан өчен кулга алына һәм Шуя шәһәренә сөрелә. Анда ул туку эшчеләрен оештыручы һәм агитатор булып әверелә. Шуяда һәм Иваново-Вознесенскида Михаил Васильевич өч ел чамасы эшли. 1907 нче ел башында аны тагын кулга алалар, аны полициягә каршылык күрсәтүдә гаеплиләр. Суд иптәш Фрунзене асарга хөкем итә; бу карар 10 ел каторга белән алмаштырыла.

Себердә М. В. Фрунзе 1909 нчы елдан 1914 нче елга кадәр сөргендә була. Аннары Иркутск губернасына күчә, яңадан кулга алына, каторгадан кача, Михайлов фамилиясе белән Көнбатыш фронтта эшли.

Октябрь революциясе көннәрендә М. В. Фрунзе баррикада сугышларына җитәкчелек итә. Иваново тукучыларының 2 меңлек отрядына җитәкчелек итеп иптәш Фрунзе „Метрополь" гостиницасына штурм ясый. Монда кораллы юнкерлар һәм башка контрреволюционерлар кереп оялаган була.

Гражданнар сугышы елларында Фрунзенең хәрби таланты киң җәелә. 1918 нче елдан башлап тормышының ахрына кадәр Фрунзе җаваплы хәрби эшләрдә эшли.

⁂

1918 нче елның декабрь ахрында Фрунзе Урал өлкәсендә хәрәкәт итүче 4 нче Кызыл Армиягә командующий итеп билгеләнә.

Ул вакытта Көнчыгыш фронтта хәл аеруча куркынычлы була. Ак гвардеецлар Совет властына каршы төп ударны шушыннан ясарга тиеш булалар. 1918 нче елның декабрендә Колчак, Архангельскига китерелгән Англия интервентлары белән кушылырга омтылып, Пермьне ала һәм 3 нче Кызыл Армиягә зур удар ясый. Пермь һәлакәтенең сәбәпләрен тикшерү бурычын партия иптәш Сталинга йөкли. Иптәш Сталин күп кенә кыю революцион чаралар күреп 1919 нчы елның январенда Көнчыгыш фронттагы хәлне сәламәтләндерүгә һәм ныгытуга ирешә. Көнчыгыш фронтның көньяк өлешендә 4 нче армиянең яңа командующие иптәш Фрунзе дә иптәш Сталин чаралары рухында эш итә. 1919 нчы елның мартында партия иптәш Фрунзегә Колчакны тар-мар итүне оештыру эшен тапшыра.

Бу куркынычлы көннәрдә Көнчыгыш фронтның көньяк өлеше армияләре (4 нче, 1 нче армияләр һәм Төркстан армиясе) нык хәлдә торалар. Шуны искә алып М. В. Фрунзе төп ударны акларның һөҗүм итеп килүче төп көчләре флангысына һәм тылына ясау планын бирә. Иптәш Фрунзенең бу гүзәл планы Иуда-Троцкийның һәм аның иярченнәренең хыянәтчел уйларын җимерә.

М. В. Фрунзе озакка сузмыйча үзенең атаклы контр ударын хәзерләүгә һәм аны тормышка ашыруга керешә. Ул удар группа төзи, сугышка аеруча сәләтле, ныклы частьләрне фронтның көньяк өлешеннән, Урал һәм Оренбург юнәлешләреннән ала һәм аларны Бузулук районына туплый.

Троцкий һәм аның иярченнәре, Колчакның Москвага баруын җиңеләйтү өчен, иптәш Фрунзегә үзенең кыю маневрын үтәргә комачауладылар. Ләкин иптәш Фрунзе үзенең планын тормышка нык үткәрә. 28 нче апрельдә Көньяк группаның каршы һөҗүме башлана һәм беренче көннәрдә үк инициатива Кызыл Армия кулына күчә.

Бу сугыш 22 көн дәвам итә. Нәтиҗәдә ак армияләр 220 километрга алып ташланалар. Колчакның баштагы уңышы бөтенләй бетерелә.

Хыянәтче троцкийчылар гаскәрләрне Көнчыгыш фронттан Көньяк фронтка күчерү сылтавы белән Кызыл Армиянең һөҗүменә яңадан тоткарлык ясарга маташалар. Көньякта исә бу вакытта Деникин һөҗүм башлаган була.

Иптәш Фрунзе икенче гаять зур операцияне—Уфа операциясен тиз арада тормышка ашыруга ныклык белән ирешергә тырыша.

Июнь башында кызыл частьләр Агыйделне үтеп чыгалар. 9 нчы июньдә Чапаев дивизиясе Уфаны ала һәм акларны Урал тавы артына алып ташлый. Уфа өчен сугышның куркынычлы моментында М. В. Фрунзе сугыш мәйданында була. Ул кулына винтовка тотып Иваново-Вознесенск тукучыларының 220 нче полкын атакага алып бара. Шушы батырлыгы өчен М. В. Фрунзе беренче Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Иптәш Фрунзе оештырган һәм үткәргән удар нәтиҗәсендә аклар 25 меңнән артык кешеләрен югалталар. Кызыл Армиянең уңышлары белән дәртләнгән эшчеләр һәм крестьяннәр Колчак тылында бер-бер артлы восстаниеләр күтәрәләр. Көнчыгышта контрреволюцияне тулысынча тар-мар итүгә нигез салына.

⁂

1919 нчы елның августында партия иптәш Фрунзене Төркстан фронтына җитәкчелек итүгә куя.

1920 нче елның 22 нче февралендә М. В. Фрунзе җитәкчелегендәге кызыл гаскәр эшелоннары Ташкентка бәреп керәләр. Төркстанда интервентларны һәм ак гвардияче бандаларны бетерү буенча озакка сузылган ныклы көрәш башлана.

М. В. Фрунзенең беренче бурычы Семиречьедәге ак гвардиячеләр фронтын тар-мар итү иде. Ак гвардиячеләргә Анненков, Дутов кебек атаклы бандитлар җитәкчелек итә иде. Бу бандалар Семиречье өлкәсенең хуҗалык тормышын таркаталар, аның халкын канлы террорда тоталар, хезмәт ияләрен талыйлар һәм көчлиләр иде.

1920 нче елның язында Семиречьедә ак гвардиячеләрнең аеруча зур бандалары бетерелә.

Төркстан хезмәт ияләренең иң явыз дошманнарына—басмачыларга каршы көрәш гаять кыен бурыч була. Чит ил интервентлары һәм барыннан да элек Англия империалистлары басмачылар бандаларыннан файдаланырга теләләр һәм басмачыларны кораллар белән тәэмин итә башлыйлар.

Политик эшне кораллы көрәш белән оста рәвештә бергә кушып М. В. Фрунзе басмачыларның төп ояларын бетерүгә ирешә ала.

⁂

1920 нче елның 21 нче сентябрендә партия М. В. Фрунзене гражданнар сугышының яңа, җаваплы участкысына, Көньяк фронтка, Врангельгә каршы җибәрә.

Советлар Россиясе әле яңа гына ак паннар Польшасы походын уңышлы төстә бетергән иде. Ләкин Донбасска һәм Украинага куркыныч тудырган тагын бер җитди дошман—барон Врангель калган иде. Антантаның бу соңгы агентын да ничек кенә булса да тизрәк бетерергә кирәк иде.

Ленин һәм Сталин бу бурычны Михаил Васильевич Фрунзегә тапшыралар. Ул Көньяк фронт командующие итеп билгеләнә.

М. В. Фрунзе Врангельне тар-мар итү буенча гүзәл план эшли. Бу планның нигезенә иптәш Сталинның 1920 нче елның җәендә тәкдим иткән планы идеясе салына.

Врангельне тар-мар итү ике операциягә бүленә. Беренче операция гражданнар сугышы тарихында „Төньяк Таврияләге сугыш" дип атала; икенчесен һәр кем белә. Ул—Перекоп янында булган тарихи сугышлар һәм Кырымны алу.

Перекоп алынырлык түгел дип санала иде. Ләкин Фрунзе монда да җиңү юлын тапты.

Перекоп җиңүе Сивашны кыю рәвештә кичү белән тәэмин ителде.

Совет хөкүмәте Врангельне тар-мар итүдә иптәш Фрунзенең гаять зур хезмәтләрен искә алып аны мактаулы революцион корал белән һәм икенче Кызыл Байрак ордены белән бүләкләде.

⁂

Гражданнар сугышы беткәннән соң М. В. Фрунзе башта СССР ның Хәрби һәм Диңгез Эшләре Халык Комиссарының урынбасары, аннары СССР ның Хәрби һәм Диңгез Эшләре Халык Комиссары итеп билгеләнә. Кызыл Армияне үзгәртеп кору һәм төзү буенча ул ныклы эш үткәрә. Фрунзе һәм К. Е. Ворошилов җитәкчелегендә 1924 нче елны „хәрби реформа" үткәрелә. Бу реформа Советлар Союзының кораллы көчләрен үзгәртеп кору буенча бөек Сталин планын тормышка ашыруга нигез сала.

1925 нче елның 31 нче октябрендә авыр операциядән соң М. В. Фрунзе үлә. Фрунзене күмгәндә партиянең һәм халыкның бөек юлбашчысы иптәш Сталин ВКП(б) Үзәк Комитеты исменнән болай диде: „Иптәш Фрунзене югалтуыбыз белән без заманыбызның иң саф, иң намуслы һәм иң куркусыз революционерыннан берсен югалттык".

Полковник *Е. Болтин.*

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

ТАТАРСТАН АССР ДА ДӘРӘҖӘЛЕ ИСЕМНӘР ҺӘМ ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ ПОЧЕТ ГРАМОТАСЫ ТУРЫНДА

1. Татарстан АССР да түбәндәге дәрәҗәле исемнәрне билгеләргә:

а) Татарстан АССР ның атказанган фән һәм техника эшлеклесе;
б) Татарстан АССР ның атказанган фән эшлеклесе;
в) Татарстан АССР ның халык артисты;
г) Татарстан АССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе;
д) Татарстан АССР ның атказанган артисты;
е) Татарстан АССР ның атказанган мәктәп укытучысы;
ж) Татарстан АССР ның атказанган врачы.

2. Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының почет грамотасын билгеләргә.

3. „Татарстан АССР да дәрәҗәле исемнәр һәм Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының почет грамотасы турында положение"не расларга.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре М. ЯКУПОВ.

Казан, Кремль.
1 февраль, 1940 ел.

ТАТАРСТАН АССР ДА ДӘРӘҖӘЛЕ ИСЕМНӘР ҺӘМ ТАТАРСТАН АВТОНОМИЯЛЕ СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ ПОЧЕТ ГРАМОТАСЫ ТУРЫНДА

ПОЛОЖЕНИЕ

1. Татарстан АССР ның атказанган фән һәм техника эшлеклесе исме яисә Татарстан АССР ның атказанган фән эшлеклесе исме фән һәм техника өлкәсендәге аеруча кыйммәтле хезмәтләр өчен, социалистик төзелеш өчен аеруча әһәмиятле булган яңалыклар һәм уйлап табулар өчен яисә күренекле фәнни-практик һәм фәнни-популярләштерүчелек эше өчен бирелә.

2. Татарстан АССР ның халык артисты исме аеруча осталыклары булган, күренекле художество образлары, спектакльләр, музыка әсәрләре иҗад иткән, Татарстан республикасының сәнгатен үстерү эшендә аеруча хезмәтләре булган театр, эстрада, цирк артистларына, режиссерларына һәм дирижерларына, шулай ук башкаручы музыкантларга бирелә.

3. Татарстан АССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе исме күренекле сәнгать әсәрләре иҗад иткән яисә художество кадрлары тәрбияләү һәм хәзерләү эшендә, шулай ук сәнгать өлкәсендә фәнни хезмәтләр иҗад итүдә зур хезмәтләре булган режиссерларга, дирижерларга, художникларга, архитекторларга, композиторларга, скульпторларга һәм сәнгатьнең башка эшлеклеләренә бирелә.

4. Татарстан АССР ның атказанган артисты исме югары дәрәҗәдә осталыклары булган, югары художестволы образлар, спектакльләр, музыка әсәрләре тудырган һәм үзләренең эшләре белән сәнгатьнең үсүенә булышлык иткән театр, эстрада, цирк артистларына һәм режиссерларына, дирижерларына, шулай ук башкаручы музыкантларга бирелә.

5. Татарстан АССР ның атказанган мәктәп укытучысы исме мәктәптә кимендә 10 ел эшләгән һәм тәрбия-педагогия эшләре белән аеруча танылган, балаларга коммунистик тәрбия бирү һәм аларны укыту эшендә күренекле уңышлар күрсәткән һәм җәмгать тормышында актив катнашкан, башлангыч, тулы булмаган урта һәм урта мәктәп укытучыларына бирелә.

6. Татарстан АССР ның атказанган врачы исме врачлык участкыларында, амбулаторияләрдә, бала тудыру йортларында, больницаларда, клиникаларда, поликлиникаларда һәм башка дәвалау-профилактика һәм санитария учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән һәм халыкны сәламәтлендерү өлкәсендә үзләренең практик эшләре белән аеруча танылган врачларга бирелә.

7. Дәрәҗәле исемнәр Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы, Халык Комиссариатлары һәм Совнарком янындагы Идарәләрнең күрсәтүе буенча Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан биреләләр.

Дәрәҗәле исемнәр бирү турында хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр Советлары һәм аларның башкарма комитетлары, партия, комсомол, профсоюз һәм башка җәмгать оешмалары үтенеч кертә алалар.

Татарстан АССР Верховный Советы президиумына кертелгән материаллар буенча профсоюзларның тиешле үзәк яки өлкә комитетларының карашы белдерелергә тиеш.

8. Татарстан АССР да дәрәҗәле исемнәр бирелгән кешеләргә Татарстан АССР Верховный Советыннан аерым таныклыклар тапшырыла.

9. Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының почет грамотасы белән Татарстан АССР ның промышленносте, авыл хуҗалыгы, транспорты, культура төзелеше, фән, техника, сәнгать, кадрлар хәзерләү, физкультура һәм спорт өлкәсендәге эштә сыйфат һәм сан ягыннан югары казанышлар күрсәткән өчен дәүләт учреждениеләре, предприятиеләр, колхозлар, җәмгать оешмалары, шулай ук аерым кешеләр—эшчеләр, колхозчылар һәм интеллигентлар бүләкләнәләр.

10. Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының почет грамотасы белән бүләкләү Татарстан АССР Совнаркомының, наркоматларның һәм Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Идарәләрнең күрсәтүләре буенча Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан башкарыла.

Хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр Советлары һәм аларның башкарма комитетлары, партия, комсомол, профсоюз һәм башка җәмгать оешмалары почет грамотасы белән бүләкләү турында үтенеч кертә алалар.

11. Татарстан АССР да дәрәҗәле исемнәрдән һәм Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының почет грамоталарыннан мәхрүм итү Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан гына эшләнә ала.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре М. ЯКУПОВ.

Казан, Кремль.
1 февраль 1940 ел.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы указы

Казан Дәүләт Медицина институтын Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының почет грамотасы белән бүләкләү турында

Медицина фәнен алга җибәрүдә һәм югары квалификацияле медицина кадрлары хәзерләүдә күренекле хезмәтләре өчен Казан Дәүләт Медицина институтын аның 125 еллыгы уңае белән Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының почет грамотасы белән бүләкләргә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре М. ЯКУПОВ.

Казан. Кремль.
1 февраль, 1940 ел.

ТАССР НЫҢ XX ЕЛЛЫГЫН ПРОИЗВОДСТВОДА ЯҢА УҢЫШЛАР БЕЛӘН ИСТӘ КАЛДЫРЫЙК!

Данлыклы юбилей хөрмәтенә социалистик ярышны киң җәелдерик!

Татарстандагы фабрикаларның, заводларның һәм төзелешләрнең барлык эшчеләренә, инженер-техник работникларына, кустарчылык-промысло кооперациясенең барлык работникларына

Кадерле иптәшләр!

Халыкларның үтәләй чергән төрмәсе — капиталистик, алпавытлар Россиясе Октябрь Социалистик Революциясенең куәтле ударлары астында җимерелде. Җир шарының алтыдан бер өлешендә кешенең-кешене эксплоатацияләве мәңгегә бетерелде. Колониаль коллыктан азат ителгән азчылык милләтләр бөек рус халкы белән иҗади дуслыкта булып үзләренең яңа, бәхетле тормышларын төзи башладылар.

Революция даһилары—Ленин һәм Сталин инициативасы буенча 1920 нче елны Татарстан АССР төзелде. Большевиклар партиясе җитәкчелегендә, бөтен Советлар Союзының ярдәме белән Татарстан кыска гына вакыт эчендә гүзәл юл үтте. Патша хөкүмәтенең артта калган, хәерче губернасы урнында, түзеп тормаслык эксплоатация изүе, хокуксызлык һәм милли изү булган урында алдынгы социалистик республика үсте. Аның байрагында Ленин ордены алтын кебек булып балкый.

Татарстанның экономикасы тамырыннан үзгәрде. Ул индустриаль-аграр республика булып әверелде. Аның заводларында һәм фабрикаларында беренче класслы техника белән коралланган йөз мең чамасы эшче эшли. Алар күпчелеге соңгы ун елда төзелгән предприятиеләрдә эшлиләр.

Авыл хуҗалыгы да зур уңышларга ирешти. Монда колхоз строе тәмам ныгыды. Искереп беткән җирләр, армый-талмый тәрбияләү аркасында, машина белән эшләү һәм ашламалар куллану аркасында элек һич тә күрелмәгән уңыш бирә башладылар. Колхоз авылы бай һәм таза тормышта яши.

Татарстан АССР үзенең химия һәм машина төзелеше заводларының продукцияләре белән генә, аяк киемнәре, мехлар, тегү әйберләре, промысло кооперациясе продукциясе, рекордлы иген уңышы һәм бик яхшы МТС лары белән генә түгел, бәлки иптәш Сталин тәрбияләп үстергән кешеләре белән дә зур дан казанды.

20 ел эчендә иптәш Сталинның мәхәббәт белән тәрбияләве аркасында сәләтле, талантлы һәм коммунизм эшенә чын күңелдән бирелгән совет, партия, хуҗалык кадрлары, промышленностька һәм авыл хуҗалыгына яңалык кертүчеләр, инженерлар, техниклар, агрономнар, врачлар, педагоглар, күп санлы совет интеллигенциясе үсте. Аларның күбесе—хезмәт сөючә татар халкы вәкилләре.

Хасан күле районында батырларча һәм геройларча сугышкан Советлар Союзы Герое Батыршины, орденлылардан тракторчы Гусевны, драматург Таҗи Гыйззәтне, шагыйрь Шәйхи Маннурны, укытучылардан Лаврованы, Абдуллинаны, стахановчылардан Әхмәдуллинаны, Вафинны, Тургеневне һәм меңнәрчә башка хезмәт геройларын һәм Кызыл Армия батырларын кем генә белми. Алар—республикабызның алтын фонды.

20 ел эчендә гаять зур эш эшләнде. Сталинчыл бишьеллыклар гаять зур күтәренкелек һәм энтузиазм белән үтәлделәр. Бездә хезмәт дан эше, батырлык һәм геройлык эше булып тора. Хәзер, Татарстанның данлыклы 20 еллыгы алдыннан, без, мехчылар—республика промышленностеның иң күп санлы отрядларының берсе, Татарстан өчен бу яңа производство тармагының ничек төзелгәнлеге турында сөйләргә кирәк дип саныйбыз.

Казандагы мех фабрикаларының барсының да биографиясе Сталинчыл беренче һәм икенче бишьеллыклар елларыннан башлана. Цехларның фундаментыннан алып технологиягә һәм кадрларга кадәр барсын да яңадан төзергә туры килде. Чит ил фирмалары мехны буяу һәм эшкәртү рецептурасын яшереп килделәр. Химикатлар барсы да диярлек чит илләрдән кертелә иде, җиһазлар һәм белгечләр юк иде. Ләкин бердәм тырышлык аркасында кыенлыкларны җиңеп чыктык. Хәзер безнең технологиябез чит ил предприятиеләренекенә караганда күп яхшырак. Җиһазларны һәм химикатларны үзебезнең промышленностебыз бирә. Бик яхшы производство базасы булдырылды, техниканы алга таба алып баручы меңнәрчә стахановчылар тәрбияләнделәр.

Куелган хезмәт әрәмгә китмәде. Партиянең тарихи XVIII нче съезды көннәрендә Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендә ярыш җәелдерелде. Производство программасы үткән елның 15 нче декабренә үтәлде. Хезмәт житештерүчәнлеге планнан тыш 16 процентка күтәрелде, планнан тыш 11 миллион сумлык сума тупланды. Соңгы вакытта комбинатта стахановчылык хәрәкәтенең яңа формалары—күп станокта эшләүчеләр һәм күп профессияләрне үзләштерүчеләр хәрәкәте үсә башлады. Казан Шәһәр Советы депутаты фрезерчы Жуков, строгаль Сергеев һәм башкалар күп станокта эшләүгә күчтеләр. 50 дән артык кеше берьюлы берничә профессиядә эшли. Слесарь хатын-кызлар өчен курслар оештырылды. Хатын-кызлар җитәкче эшкә кыю рәвештә күтәреләләр. Фабрика техноругы Арапова, 3 нче фабрика директоры Кикоть, механика заводының цех начальнигы Насырова, һ. б. иптәшләр комбинат цехларында тәрбияләнделәр, производство командирлары итеп күтәрелделәр.

1939 нчы ел стахановчылык методларын тирәнтен өйрәнү билгесе астында үтте. Стахановчы иптәш Шаткова үзенең эш тәҗрибәләрен уртаклаша. Аның лекцияләре нык уйланылган һәм яңа нәрсәләргә бай була. Иванов, Чекалкина, Әшрәфҗанов, Герасимова, Бикмуллина, Бочкарева һәм башка иптәшләр стахановчылар мәктәпләренә җитәкчелек иттеләр. Шул ук вакытта производствоның иң яхшы кешеләре өчен фабрикаларда стахановчыларның техника мәктәпләре оештырылды. Бу мәктәпләрдә 400 стахановчы үзләренең белем дәрәҗәләрен инженер-техник работниклар белеме дәрәҗәсенә кадәр күтәрәләр.

Турыдан-туры әйтергә кирәк, безнең предприятиеләрдә әле файдаланылмаган зур гына резервлар бар. Ирешелгән уңышлар чик түгел, бәлки тагын да зуррак уңышларга бару юлындагы этап кына.

Орденлы Татарстанның хезмәт ияләре!

Безнең коллектив республикабызның XX еллык юбилеен ярты еллык программаны срогыннан алда үтәү белән билгеләп үтәргә карар бирде. СССР Җиңел Промышленность Наркоматыннан алынган задание үткән елдагыга караганда шактый югары. Ләкин без үз көчләребезне беләбез һәм илебезгә, потребительгә планнан тыш продукция бирәчәгебезне белдерәбез.

Без үз өстебезгә түбәндәге йөкләмәләрне алабыз:

25 нче июньгә алты айлык программаны тәмам итәргә.

Бездә эшләп чыгару нормаларын үтәмәүче бер генә эшче дә булмас.

Хезмәт житештерүчәнлеген 1939 нчы ел белән чагыштырганда 15 процентка күтәрергә.

Производствога рационализаторлык такдимнәрен кыю төстә кертергә, шул исәптән кыйммәтле сабынны бик яхшы алмаштыручы булган керосин контактын массовый күләмдә кулланырга.

500 тонна күмергә, 300 мең киловатт электроэнергиягә экономия ясарга. Ярым фабрикатларның файдаланыла торган мәйданын 3,7 процентка, прикладны—1,5 процентка арттырырга.

Берьюлы берничә профессиядә һәм күп станокларда эшләүне, хатын-кызларның яңа профессияләрне үзләштерүләрен киң кулланырга.

Алдынгы штатлы нормативлар эшләп чыгарырга һәм аларны тормышка үткәрергә.

Без үзебезнең башлап җибәрүебез Татарстан фабрикаларында, заводларында һәм төзелешләрендә киң күләмдә күтәреп алыныр дип ышанабыз.

Орденлы Татарстан республикасының XX еллыгын лаеклы төстә каршылау өчен социалистик ярыш җәелдерик, иптәшләр.

Иптәшләр, энергетиклар!

Бер генә авария булуга да, потребительгә ток бирүне аз гына туктатуга да юл куймагыз. Ягулыкка экономия ясагыз. Шлакны сыек төстә чыгарып ташлау буенча үзегез эшләп чыгарган методка тизрәк күчегез.

Станокларның бер минут туктап торуы хезмәт җитештерүчәнлеген киметкәнлекне, продукция чыгаруны киметкәнлекне онытмагыз.

Җиңел индустрия эшчеләре!

Илебез сездән киң куллану товарлары, күбрәк аяк киеме, тегү нәрсәләре, тканьнар көтә, отходлар санын киметегез, фабрика маркасының данын югарырак күтәрегез.

Казанның, Зеленый Долның, Чистайның машина төзүчеләре!

Партиянең XVIII нче съезды күрсәтмәләрен исегездә тотыгыз, станокларның һәм машиналарның яңа, яхшыртылган үрнәкләрен үзләштерегез. Күп станокта эшләүгә күчү өчен сездә чиксез зур мөмкинлекләр бар, станокларга өстәмә уңайлыклар эшләп чыгарыгыз. Иван Гудов тәҗрибәсеннән файдаланыгыз, техникадан ахрынача файдаланыгыз.

Булдырь, Шөгер, Кама Тамагы нефтьчеләре!

Татарстан иң якын вакыт эчендә Икенче Бакуның алдынгы участкысы булып әверелергә тиеш. Нефть разведкасын кызу төстә алып барыгыз. Структураларны тизләтелгән методлар белән бораулагыз, ротор һәм крелиус станокларының эшсез торуларына юл куймагыз.

Ленин исемендәге заводның, 4 нче ясалма каучук заводының, жиркомбинатның, кинопленканың һәм Бондюг заводының стахановчылары!

Төгәл һәм кызулатылган тигез темп белән эшләгез. Сезнең резервларыгыз зур, гүзәл кадрларыгыз бар, ярышның алдында барыгыз.

Кустарь промыслосы кооперациясенең работниклары!

Сез заданиене шактый арттырып үти аласыз. Эшләп чыгарыла торган нәрсәләрнең сыйфатына, ассортиментны арттыруга аеруча игтибар бирегез, чималны экономия белән тотыгыз, промышленностьның күп санлы отходларыннан тулысынча файдаланыгыз.

Кадерле иптәшләр!

Безнең данлыклы Кызыл Армия Финляндия хезмәт ияләрен азат итеп, маннергеймчы-таннерчы бандага онтылмаслык сабаклар биргән көннәрдә, сугышчыларыбыз, командирларыбыз һәм политработникларыбыз геройлык һәм батырлык үрнәкләре күрсәткән көннәрдә стахановча эшләп Ватаныбызның куәтен, социализм иленең оборона сәләтен тагын да ныгытыйк.

Орденлы Татарстан промышленностенең яңа гүзәл җиңүләре өчен ярыш байрагын югарырак! Республикабызның XX еллыгын лаеклы каршылауда катнашмаган бер генә эшче дә, инженер-техник работник та, хезмәткәр дә калмасын!

Данлыклы юбилеебезне стахановчыларча яңа эшләр белән истә калдырыйк!

Барыбыз да тагын да яхшырак эшлик! Иптәш Сталин өйрәткәнчә эшлик.

Яшәсен юлбашчыбыз һәм остазыбыз, беренче Социалистик Хезмәт Герое бөек Сталин!

Мөраҗәгать Казан мехкомбинаты эшчеләренең, инженер-техник работникларының һәм хезмәткәрләренең гомуми фабрика җыелышларында кабул ителде.

РӘСЕМДӘ: „Спартак" комбинатының (Казан) Кызыл байраклы унтовой цехы стахановчысы иптәш А. А. Прасвернова. Иптәш Прасвернова көнлек норманы 140 процентка үти.
Лаврентьев фотосы.

Юл төзү эшенә игтибар итмиләр

Лаиш районы үзенең автотранспорт юллары белән һич тә мактана алмый. Бу районда Чкалов тракты чикләре эчендә генә дә ат һәм автомашина белән үтеп йөри алмаслык 10 километрдан артыграк участкы бар. Ләкин район оешмалары, материаль яктан зур зарар китерә торган бу юлсызлыкка килешүчәнлек белән карыйлар.

Казан—Чистай—Бөгелмә трактын төзекләндерү турында Столбище районы колхозчылары мөраҗәгатенә районда бары „Путь Ленина", „Активист" һәм Нариманов исемендәге колхозлар гына кушылдылар. Бу колхозлар юл төзү материалларын ташу планын үтәү буенча районда иң алдынгы колхозлардан саналалар һәм алар да еллык планның 50 проценты үтәлгән дә инде. Ләкин ВКП(б) райкомы, шулай ук райбашкарма комитеты бу алдынгы колхозларның инициативаларына җитәкчелек итмиләр. Нәтиҗәдә, Столбище районы колхозчыларының мөраҗәгате Лаиш районының башка колхозларында шушы көнгә кадәр бөтенләй өйрәнелмәгән дә.

Бирегә юл төзүчеләр район оешмалары тарафыннан бу эшкә бәя бирелеп җиткерелмәү фактларын сөйлиләр. Ферганә каналы төзелешенең бай тәҗрибәсен республикабызның юллар төзелешенә күчерү турындагы мәсьәлә белән әле шушы көнгә кадәр авыл советлары һәм колхоз председательләренең район киңәшмәсе үткәрелмәгән. Дөрес, юл төзелеше работникларының куст җыелышында бу турыда кыскача „информация" куелган. Ләкин көн тәртибенә иң ахыргы мәсьәлә итеп кертелгәнлектән бу „информация"нең бер төрле дә нәтиҗәсе булмады.

Ул гына да түгел. Кайбер авыл Советларының һәм колхозларның председательләре, район оешмалары җитәкчеләренең юл төзү эшенә шулай салкын караулрыннан файдаланып, агач материалы, таш, гравия ташу өчен моңа кадәр билгеләнгән олауларның санын тагын да киметүгә кадәр барып җиткәннәр. Хәзер Чкалов трактына төзү материаллары ташу эшендә 600 олаучы урнына бары 30—35 олаучы эшли. Төзү материаллары ташу планы бары 7 процентка үтәлгән.

Шуран авыл советына караган „Красная Поля" колхозы председателе Кирюшин „райбашкарма комитетыннан күрсәтмә булмауны" сылтау итеп, атлар һәм эшчеләр бирүдән бөтенләй баш тарта. Тарту көчләре белән тулысынча тәэмин ителгән „Красная Звезда" һәм „Красный Доль" колхозлары әле материалларны төзү объектларына ташу эшенә бөтенләй керешмәгәннәр дә. Бу колхозларның председательләре Носанов һәм Росков юл төзү эшенә бөтенләй эшкә яраксыз атлар бирәләр.

Район оешмаларының юл төзү эшенә салкын караулары бөтен җирдә күзгә бәрелеп тора. 69 колхозның 6 сында гына юл төзү бригадалары оештырылган. Юл төзү материалларын хәзерләү һәм аларны ташу буенча үзләренең йөкләмәләрен усал ният белән үтәмәүче ялгыз хуҗалыкчыларга карата бер нинди да чара күрелми. Ә район юл төзү бүлеге начальнигы Новиков һәм массовик Чупина иптәшләр райбашкарма комитетының аерым поручениеләр белән йөрүче агентларына әверелгәннәр.

Юл төзү бүлеге начальнигы иптәш Новиковның кат-кат соравына да карамастан, ике ел ярым вакыт эчендә ВКП(б) райком бюросында аның бер генә дә доклады тыңланмаган.

Менә, ВКП(б) райкомы һәм райбашкарма комитеты җитәкчеләренең Столбище районы колхозчыларының чакыруына формаль рәвештә генә карауларын күрсәтә торган тагын бер факт. Мөраҗәгатьне укыганнан соң ВКП(б) райкомының икенче секретаре иптәш Данилов председательлеге астында юл төзү эшләре буенча махсус комиссия төзелгән. Ләкин бу комиссия коры сөйләнүләрдән ерак китә алганы юк.

Шушы көннәрдә ВКП(б) райкомының пленумы булып үтте. Райком секретаре иптәш Огольцов пленум ябылыр алдыннан, пленумда катнашучыларга бер сорау бирде.

— Столбище районы колхозчыларының мөраҗәгатен барыгыз да укыдыгызмы?—диде ул.

— Барыбыз да,—дип җавап бирде, залдагылардан берсе.

— Бик яхшы, эшкә башлагыз,—диде иптәш Огольцов.

Ләкин райком секретаренең мондый яхшы теләкләре, кызганычка каршы, конкрет чаралар белән ныгытылмаганлыктан, нәтиҗәсез калдылар.

Нәтиҗә ачык. Чкалов трактын Ферганә колхозчыларының методы белән конструкцияләү турында Столбище районы колхозчыларының гүзәл такдимнәре Лаиш районында үзләренә урын тапмадылар әле. Биредә юл төзү эшенә икенче чираттагы эш дип карау әле һаман да яшәп килә.

А. Никольский.
К. Биков.

Чит илләрдә

Гитлер рече

БЕРЛИН, 31 январь. (ТАСС). Кичә кич белән, национал-социалистларның властька килүе еллыгына багышланган тантаналы җыелышта, Гитлер речь сөйләде. Бу речендә ул болай диде:

Германия шундый шартларда тора ки, аның белән булган сугышта беренче чиратта Англия тарафыннан куелган гаҗәп төстәге хәрби максатлар тормышка үткәрелә. Хәрби максатларны иглан итү эшендә Англиянең зур тәҗрибәсе бар, чөнки дөнья тарихында сугышларның күпчелеген ул алып барган. Шул максатлар нигезендә, яңа Европа барлыкка килергә тиеш. Бу Европа гаделлекне аңлау белән сугарылган булырга тиеш һәм шушы гомуми гаделлек коралларны артык бер нәрсә итеп калдырырга тиеш. Коралсызлану аркасында экономик чәчәк ату, сәүдә һәм культура күтәрелеше заманы башланырга тиеш. Кыскасы, ниһаять, алтын гасыр башланырга тиеш. Бу алтын гасырны, кызганычка каршы, безгә инде бер тапкыр сурәтләп күрсәткәннәр иде, әйтергә кирәк, шул ук кешеләр күрсәткән иде. Болар барсы да 1918 нче елны ук вагдә ителгәннәр иде инде.

Ләкин, нәрсә булды соң? Халыкларның үз язмышларын үзләре билгеләү хокукы белән санашмыйча, Европаны бүлгәләделәр, гаять зур дәүләтләрне кисәкләргә аердылар, халыкларны бастырдылар, ә милләтләрне, иң элек коралсызландырып, хокукларыннан мәхрум иттеләр аннан соң коралсызлану турында сөйләми башладылар, киресенчә, торган саен күбрәк күләмдә коралланырга керештеләр. Конфликтлар бер вакытта да тыныч юл белән хәл ителмәделәр, киресенчә, кораллы дәүләтләр, аңа кадәр булган шикелле үк, сугыш алып бардылар. Шулай ук, экономик чәчәк ату заманы да килмәде. Киресенчә, репарацияләрнең буталчык системасы җиңелгән илләрне генә түгел, бәлки җиңүче булып чыккан илләрне дә экономик мохтаҗлыкка алып килде. Культура өлкәсендә дә шулай ук һичбер прогресс булмады.

Аннан соң Гитлер, Версаль системасы тарафыннан Германиянең коллыкка төшерелгән булуын бетерүне национал-социалистик хәрәкәтнең үз бурычы итеп куйганлыгын аеруча күрсәтеп үтте һәм Германиянең куәтен урнаштыру өчен Германия хөкүмәте тарафыннан үткәрелгән чараларны санап чыкты.

Гитлер болай дип белдерде: „Бик еш вакытларда, барлык бәхәсле мәсьәләләрне без сөйләшүләр юлы белән хәл итә алыр идек, диләр. Германиянең колониаль таләпләре мәсьәләсен сөйләшүләр юлы белән хәл итәргә мин берничә тапкыр такдим итмәдеммени? Моңарга без нинди җавап алдык соң? Бары тик „юк“ дигән җавапны гына алдык, бары тик безнең таләпләрне кире кагуны һәм яңа кылануларны гына күрдек. Әгәр дә бүген Чемберлен шикелле бер әфәнде чыгып сөйли икән һәм закон чыгаручы сыйфатында бөтен дөньяга үзенең хәрби максатларын иглан итә икән, ул вакытта мин бары тик: мистер Чемберлен, сезнең үз тарихыгыз үзегезне инкар итә, дип кенә әйтә алам. Өч йөз ел буе сезнең дәүләт эшлеклеләрегез сугышлар башланган вакытта һәр вакыт сез бүген сөйләгәнне сөйләп килделәр. Алар гүяки бары тик алла һәм дин өчен генә көрәш алып бардылар. Ләкин шул өч йөз ел эчендә сез үзегезгә 40 миллион квадрат километрга якын мәйданнан гыйбарәт булган территорияне буйсындырдыгыз. Англия алланы яклаучы ролендә бер вакытта да үзе генә чыгарга теләмәде, бәлки үзе тарафыннан тудырыла торган конфликтларда катнашырга башкаларны да чакырды. Англичаннар шушыны ук хәзер дә эшлиләр.

Чынында Англия үзенең сәүдәсен киңәйтү өчен, алтын һәм алмаз чыганакларын басып алу өчен сугышлар алып барды. Болар барсы да, гәрчә яхшы идеаллар белән яшеренгән булсалар да, бары тик материаль максатлар гына иделәр. Карт Чемберлен үз эченнән генә уйлый торган нәрсәне мистер Черчилльнең ачыктан-ачык әйтеп бирүе өчен, мин Черчилльне мактыйм. Черчилль: „Безнең максатыбыз Германияне бүлгәләүдән һәм юк итүдән гыйбарәт“ ди. Сүзнең нәрсә турында баруын ачыктан-ачык әйтүче француз генералларын котлаган шикелле үк, мин бу ачыктан-ачык әйтүне дә котлыйм. Аларның нинди максат куйганлыкларын без тәмам ачык беләбез: алар бүлгәләнгән Германия булдырырга телиләр. Әгәр дә вак дәүләтләр протест ясыйлар икән яки үзләренең тормыш хокукларына карата таләпләр куялар икән, ул вакытта безнең дошманнарның кайсысы моңарга игтибар бирә соң? Ләкин әгәр дә 80 миллион кеше үзенең таләпләре белән чыга икән, ул вакытта эш икенче төрле тора. Шунлыктан, безнең дошманнар үз вактында Италиянең берләшүенә һәм Германиянең дәүләт булып берләшүенә дошманлык белән карадылар. Алар бу дәүләтләрне үзләренең элекке аерылмас өлешләренә бүлгәләргә барыннан да күбрәк теләделәр. Үзенең тирәсендә бәхәс бара торган проблема әнә шуннан гыйбарәт. Алар йөз еллар буе гаять зур милләтләрне бары тик аларның берләшмәгән булулары аркасында гына алдап килделәр. Ләкин хәзер бу милләтләр үзләренең бүлгәләнгән булуларын бетерделәр“.

Аннан соң Гитлер, 46 миллион англичанның 40 миллион квадрат километр территориягә ия булуы фактын, ә Франциянең 9 миллион квадрат километрдан артык территориягә ия булуы, шул ук вакытта 80 миллион халыклы Германиянең хәтта 600 мең квадрат километр территориясе дә булмау фактын тагын бер тапкыр аеруча күрсәтеп үтте. Хәл ителергә тиешле проблема әнә шул.

„1939 нчы елны көнбатыш державалар масканы ташладылар һәм Германиягә сугыш иглан иттеләр. Сугышны булдырмауга карата безнең барлык омтылышларыбызга карамастан, алар безгә сугыш иглан иттеләр. Бүген алар моны оятсыз рәвештә үзләре икрар итәләр. Әлбәттә, Польша мәсьәләсе буенча, ихтимал, сөйләшеп килешергә мөмкин булган булыр иде. Ләкин алар моны теләмәделәр. Алар сугыш теләделәр. Мин кулымны бирдем, алар аны кире кактылар. Алар: „Һичбер татулану, һичбер килешү юк, бары тик көрәш кенә бар“ дип кычкырдылар. Яхшы, алар бу көрәшне алдылар“.

Аннары Гитлер дуслык һәм чик турында Совет—Германия договорының әһәмиятенә тукталды.

„Чемберлен ирешә алмаган нәрсәгә ирешүебез уңае белән Англиядә котырыну хәленә килүләрен мин аңлыйм. Чемберлен, үзе ирешергә теләгән нәрсә аллага кирәк, ә безнең тарафтан ирешелгән шул ук нәрсә аллага кирәкми, дип уйлый. Шулай да, мин уйлыйм ки, гаять зур территориядә магнәсез сугышны булдырмауны кодрәт иясе яхшы дип табар“. (Кул чабулар). „Германия белән Россия күп йөз еллар буе тынычлыкта һәм дуслыкта яшәделәр. Ни өчен соң бу киләчәктә дә була алмасын? Мин, бу мөмкин, дип уйлыйм. Чөнки һәр ике халык аны телиләр. Британия яки Франция плутократиясенең безне бәрелешүгә котыртырга һәр төрле омтылышлары уңышсызлыкка дучар ителгән“. „Безнең Польшага каршы көрәшебез иң кимендә ярты ел яки бер ел дәвам итәр, дип Англия хәрби экспертларының ышанулары безнең кораллы көчләребезнең куәте белән юкка чыгарылды. Англия үзенең гарантияләрен биргән дәүләт, вагдә ителгән гарантияләрнең үтәлүен күрә алмыйча ук, Европа картасыннан 18 көн эчендә юкка чыкты. Шуның белән сугышның беренче фазасы тәмам булды. Аның икенче фазасы башлана. Черчилль әфәнде инде сугышның бу икенче фазасын башлау теләге белән сөйли. Ул, инде, ниһаять, бомбалар ярдәме белән сугыш башланачак, дигән нәрсәгә ышанычны белдерү эшен арадашлык итүчеләргә тапшыра, ә кай вакытларда үзе дә белдерә. Алар инде, бу сугышта хәтта хатын-кызлар белән балаларны юк итү алдында да тукталып калмаячаклары турында язалар. Англиянең кайчан да булса моның алдында тукталып калганы бармени? Бөтен блокада хатын-кызларга һәм балаларга каршы сугыш булып тора бит. Бур халкына каршы сугыш та шулай ук хатын-кызларга һәм балаларга каршы сугыш иде. Концентрация лагерлары нак әнә шул вакытта уйлап чыгарылды. Ни өчен соң Англия хәзер башка средстволар белән көрәшсен? Моны без алдан ук күрдек һәм аңарга хәзерләндек“.

Германия халкының бердәмлегенык булуга шик белдергән Франция премьеры Даладьеның соңгы чыгышына тукталып, Гитлер, реченең ахрында, болай дип белдерде:

„Безнең дошманнар: „Германия һәлак булырга тиеш“ дип кычкыралар. Моңарга Германия бары тик бер генә җавап бирә ала: „Германия яшәячәк; Германия җиңәчәк!“.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Үзәк Кытайда

31 нче январьда кытай частьләре бөтен көн буе японнарның Сяошаньдәге позицияләренә атака алып бардылар. Японнар каты каршылык күрсәттеләр һәм төн уртасына кадәр шәһәрне үз кулларында тоттылар.

„Даваньбао“ газетасының махсус хәбәрчесе тарафыннан бирелгән мәглүматларга караганда, курчак властьлар гаскәрләренең берничә йөз солдаты Сяошаньда восстание күтәргәннәр. Японнар белән булган атышудан соң восстаниечеләр группасыннан 50 гә якын кеше шәһәр әйләнәсендәге стена аркылы чыгып, милли хөкүмәт гаскәрләренә кушылганнар.

Ханчжоу районында операция алып бара торган кытай гаскәрләре Ханчжоуның үзендәге һәм Гунчэньцзяо (Ханчжоудан төньякка таба 10 километрда) тимер юл станциясендәге япон гарнизонына атака ясадылар.

Хубэй провинциясенең үзәк өлешендә, Янцзычэн (Чжунсяннан төньякта) секторында, 29 һәм 30 нчы январьда японнарның 300 гә якын кешеләре үтерелде һәм яраланды. Бу секторда японнар кытайларның позицияләренә берничә атака ясадылар, ләкин атакалар көчле артиллерия уты ярдәме белән алып барылган булуына карамастан, аларның бөтен тырышлыклары бушка китте.

Төньяк Кытайда

Суйюань провинциясендә, Баотоу районында, япон гаскәрләре 27 нче январьда, 6 мең кешегә якын өстәмә көч алып, ике колонна булып һөҗүм башладылар. Японнарның бронялы 30 йөк автомобиленнән торган бер колоннасы көнбатыш юнәлешендә, Баотоу—Уюань арасындагы шоссе юлы буйлап хәрәкәт итә. Бронялы 110 йөк автомобиленнән торган икенче колонна Баотоудан төньякта Хуанхе елгасын аркылып чыкты. Хәзер Уларань таулары районында (Баотоудан көнбатышка таба 50 километрда) япон һәм кытай гаскәрләре арасында сугышлар бара. Хәбәр итүләренә караганда, японнар, бу районда һөҗүм алып барып, Суйюань провинциясенең көнбатыш һәм төньяк өлешләрендә ныгырга, биредә тиешле базалар хәзерләргә һәм, шуларга таянып, Нинся һәм Шэньси провинцияләренә бәреп керергә телиләр.

Көньяк Кытайда

30 нчы январьда кытай гаскәрләре Тайпинчэньнан (Кантоннан төньякта) һәм Шэньканнан (Кантоннан төньяк-көнчыгышта) японнарны кысрыклап чыгардылар. Японнарның, чигенгән вакытта, бик күп кешеләре үтерелде һәм яраланды.

„Дамейбао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, 28 нче январьда кытайларның зенит артиллериясе японнарның бер самолетын бәреп төшергән.



„И. Сталин“ бозваткычы Гренландия диңгезендә. Д. Дебабов фотосы. (ТАСС фото-клишесе).

Ә. ГӘРӘЙ.

ДИҢГЕЗ ӘКИЯТЕ

Шаулый салкын океан...
Өрә авыр җилләр...
Күтәреләләр бозлар
Текә тау булып,
Тюлень аулап йөри
Монда ак аюлар,
Бер бозларга сикереп,
Бер аска чумып.

Яши шулай ялгыз
Ерак боз дөньясы,
Була алмыйча кешегә
Нидус, ни дошман,
Ята шунда дулап
Җилләр, бозлар белән,
Кул селтәгән төсле
Рәтле тормыштан.

Ак аюлар гына
Күргәләде анда,
Кешеләрнең нидер
Эзләп килүен,
Күбесенең сугышып
Бозлар, җилләр белән,
Ялгыз килеш туңып,
Ачыгып үлүен...

Арада иң күпне
Күргән бер карт аю,
Балаларына сөйли
Тирән бер әкият:
„...Белмим кеше нигә
Килеп йөри монда,
Ни теләк аңарда,
Нинди зур ният?...

Бик күбесе инде
Минем күз алдымда
Үлеп калды менә
Шушы бозларда...

Һаман курыкмыйлар,
Һаман тукталмыйлар,
Үзем куркам хәтта
Шуны уйларга.

Соңгы заманнарда
Бигрәк күп киләләр,
Бик гәйрәтле нәсел
Ахры болары...
Һич юк иде әле
Кешеләрнең монда,
Болай озак итеп
Исән торганы.

Күптән түгел генә,
Дүртәү шул нәселдән
Бер ел яшәп, аннан
Очып киттеләр.
Күп үтмәде, утырып
Корыч балыкларга
Бүтәннәре тагын
Килеп җиттеләр.

„Седов“ дигән берсе
Озак йөзде монда,
Бер дигәннәр анда—
Яшьләр, иптәшләр,
Болары да тырышып
Нидер эзләделәр,
Юкка гына алар
Болай йөрмәсләр...

Исән, таза килеш
Китте һәммәсе дә,
Моңаймагыз ләкин,
Тагын килерләр,
Менә безнең кебек
Җилне-нине белми,
Шушы бозлар белән
Уйнап йөрерләр.

Карт ак аю сөйли
Булган бу әкиятне,
Балалары җыелып,
Йотылып тыңлыйлар...
Ачуланган бозлар
Сикереп бер-берсенә,
Басып сытар өчен
Корбан сорыйлар...

Боз өстендә утырып.
Аю уйга баткан,
Ул океанны сүгә,
Улый җилләргә:
„...юл бирмәскә телисең
Батыр кешеләргә,
Бозларыңны ватып
Иркен йөзәргә.

Җиңә алмассың барыбер
Туры килер сиңа
Буйсынырга кешенең
Яңа нәсленә,
Шушы кешеләр белән
Тату, дус торырга
Мин дә васыят әйттем
Инде нәслемә...“

Шаулый салкын диңгез,
Өрә авыр җилләр...
Боз тауларын җимереп,
Бара зур караб,
Бер хәвефсез, тыныч
Йөзсен өчен кешеләр
Мәңгелек һәм матур
Яңа юл карап.

1940 ел, январь.

ХАЛЫКАРА ХӘЛ ТУРЫНДА ЛЕКЦИЯ

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатының лекцияләр бюросы Казан Кызыл Армия Йорты белән берлектә, 26 нчы январьда халыкара хәл турында лекция үткәрде. Лекцияне Волга Буе Хәрби Округыннан батальонный комиссар иптәш Грановский укыды.

Лектор үзенең лекциясендә Европада бара торган сугыш, аның характеры һәм сугышучы илләрнең политикалары турында сөйләп, СССР белән Германия һәм СССР белән Балтыйк буе илләре арасында төзелгән тынычлык һәм дуслык договорларына тукталды. Икенче империалистик сугышны тудырган сәбәпләргә анализ ясады һәм беренче империалистик сугыш белән чагыштырып, хәзерге сугышның тактикасы һәм стратегиясе турында аңлатты.

Аннан соң лектор „нейтраль“ илләрнең политикалары турында, аерым алганда, Америка Кушма Штатлары, Италия һәм Япония турында сөйләде.

Финляндиядәге вакыйгаләргә күчеп, фин халкын Маннергейм бандаларыннан азат итү юлында данлыклы Кызыл Армия тарафыннан фронтларда күрсәтелгән батырлыклар турында сөйләде. Соңыннан Кытайдагы сугыш хәрәкәтләренә, Япония белән СССР ның мөнәсәбәтләренә тукталды.

Залда утыручылар лекцияне зур кызыксыну белән тыңладылар һәм лекция буенча күп кенә сораулар бирделәр.

Лекцияне тыңларга 750 кеше килгән иде. Киләсе лекция „СССР һәм аның Балтык буе күршеләре“ дигән темада февраль башларында булачак.

Сәүдә работниклары өчен техминимум түгәрәге

Әлмәт райпотребсоюзы янында сәүдә работниклары өчен техниканы үзләштерү түгәрәге оештырылды. Хәзер инде түгәрәктә биш дәрес үткәрелде. Укуга 35 ләв сәүдә работнигы йөри. „Халык хуҗалыгында совет сәүдәсенең әһәмияте“ дигән темадагы лекцияләрне түгәрәк членнары аеруча ярату тыңлыйлар. Түгәрәкне оештыруда райпотребсоюзның инструкторы Харрасов һәм Габидуллин иптәшләр якыннан торып катнаштылар.

А. Мусин.

Алдынгы умартачылар бүләкләнделәр

РСФСР Җир Эшләре Халык Комиссариатының махсус приказы белән 1939 нчы елда умартачылыктан бал һәм балавызның югары уңышын алган алдынгы умартачылар мактау грамотасы һәм акча белән бүләкләнделәр.

Бүләкләнүчеләр арасында татарстан республикасының алдынгы стахановчы умартачыларыннан 11 кеше—Кызыл Йолдыз районы „Красный Дол“ колхозы члены Матвеев, шул ук район „Колос“ колхозы члены Алимов, Мөслим районы „РККА“ колхозы члены Калашников, Сарман районы „Алмас“ колхозы члены Бәдерттинев, Саба районы „Тукай“ колхозы члены Фәлахов, Әлмәт районы „Нәриман“ колхозы члены Юсупов һәм башка иптәшләр бар. Боларның һәр кайсы умартадан уртача 60—100 килограмм бал, 1 килограмм балавыз алганнар.

Умарта кортларында була торган авыруларга каршы яхшы көрәшкән умартачыларны бүләкләү өчен 12 мең сум акча җибәрелде. 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашучыларның санын тагын да арттыру өчен умартачылар арасында көрәш җәелдерелде. 1940 нчы елда Күргәзмәгә катнашу өчен 43 колхоздан һәм аерым умартачылардан гаризалар алынды.

Г. Хәкимов.

КӨТЕПХАНӘДӘ

Әтнә районының үзәк көтепханәсе (мөдире Сибгатуллин) хезмәт ияләре арасында зур популярлык белән файдалана. Көтепханә елы, якты һәм матур итеп бизәлгән. Анда 10.925 китап бар. Шулардан политик темаларга 2.501, авыл хуҗалыгы буенча 1.100, матур әдәбият буенча 4.313, балалар әдәбияты буенча 700 китап бар. 1939 нчы елда 5.300 кеше көтепханәдән китап алып укыган.

ВКП(б) тарихын үзлекләреннән өйрәнүче күп кенә иптәшләр көтепханәдән яхшы файдаланалар. Алар биредә өстәмә материалларны укыйлар, диаграммалардан, карталардан файдаланалар.

Көтепханә районның 32 урнында күчмә көтепханә оештырды һәм аларны 6.252 китап белән тәэмин итте.

Көтепханәнең актив укучыларыннан 71 яшьлек Гариф Маннапов, 51 яшьлек Галим Садыйков иптәшләр соңгы вакытларда „Күтәрелгән чирәм“, „Корыч ничек чыныкты“, „Капитан Грант балалары“ һәм башка китаплар укып чыктылар.

Көтепханәдә хезмәт ияләре өчен дингә каршы темаларда, партия һәм хөкүмәт карарларын аңлату буенча беседалар, лекцияләр, докладлар үткәрелә.

Хәбибуллина, Хөсәенев.

Җаваплы редактор Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Казан Дәүләт Ветеринария институтының паталогик анатомия кафедрасы аудиториясендә түбәндәге темаларда халык алдында

ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАУ ҮТКӘРЕЛӘ

13 нче февраль, кич 5 сәгаттә, ветеринария фәннәре кандидаты дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен

1. Немец Авыл Хуҗалыгы институтының генетика һәм авыл хуҗалыгы терлекләрен үрчетү кафедрасының мөдире хезмәтләрен үтәүче А. Н. Мирошкин Тема: Сыерларның бозау салуының сәбәпләрен анализлау һәм сыерларның бозау салуларын булдырмау чаралары.
Рәсми оппонетлар: профессор доктор П. Я. Сырнев һәм фәннәр кандидаты доцент А. М. Басрков.

2. Киев Ветеринария институты ассистенты В. К. Чубар. Тема: „Атларның индивидуаль яшәү шартлары тарихы ягыннан, атның борын тирәсе синуслары“.
Рәсми оппонентлар: фәннәр кандидаты доцент Н. А. Васнецов һәм фәннәр кандидаты доцент В. Г. Зайцев.

19 нчы февраль, кич 5 сәгаттә, ветеринария фәннәре докторы дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен.
Киров Ветеринария институты доценты А. А. Банников Тема: „Сәламәт һәм туберкулез авырулы мөгезле эре терлекләрнең каннарында тубекулез реакцияләре вактында морфологик үзгәреш“.
Рәсми оппонентлар: профессор доктор Н. П. Рухлядов, профессор доктор Б. Л. Мазур һәм профессор доктор М. В. Рево.
Диссертация материаллары белән институт көтепханәсендә таншырга мөмкин.
167—1

„Главкинопрокат“ ның Татарстан конторасы шушы көннәрдә Казан шәһәре кино-экраннарына
УНБЕР БАШКАЛА
исемле хроникаль-документаль яңа фильм бирә.
„ГЛАВКИНОПРОКАТ“.
163—1

ВОДОКАНАЛ
КАЗАН ШӘҺӘРЕ ХАЛКЫНА БЕЛДЕРӘ:
Кабан күленә Волга промводопроводыннан су кертү нәтиҗәсендә Кабан күле өстендә туңмый торган урыннар барлыкка килде.
Шуның өчен, Татарстан АССР ның 3 еллыгы исемендәге электростанциядән „Спартак“ комбинатына һәм су станциясенә кадәр булган урыннарда Кабан күле өстендә авто һәм атлы транспортның йөрүе, шулай ук җәяү кешеләрнең йөрүләре тыела.
163—1

КИРӘК:
„Кызыл Күнче“ заводына ашыгыч рәвештә РАСЧЕТ БҮЛЕГЕ БУХГАЛТЕРЫ, АШХАНӘ БУХГАЛТЕРЫ, ЦЕХ ХИСАПЧЫЛАРЫ, КАРТОТЕКАЧЫЛАР, КҮН ЭШЧЕЛӘРЕ һәм СЛЕСАРЬЛАР.
171—1

Казэнергокомбинатка даими эшкә ИНЖЕНЕР-ЭЛЕКТРИКЛАР, ЕНЖЕНЕР-ТЕПЛОТЕХНИК, НОРМАЛАУЧЫЛАР, ТЕПЛОТЕХНИКЛАР, БАШ БУХГАЛТЕР УРЫНБАСАРЫ, БУХГАЛТЕРЛАР, ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР, СЛЕСАРЬЛАР, финанс бүлеге өчен ЖИТӘКЧЕ һәм нормалау буенча ӨЛКӘН ИНЖЕНЕР. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Тукай урамы, 139.
164—1

Таткинотрестка даими эшкә БУХГАЛТЕРЛАР, БУХГАЛТЕР ЯРДӘМЧЕСЕ, ХИСАПЧЫЛАР һәм КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ МАШИНИСТКА. Казан, Бауман урамы, 60. Баш бухгалтерга килергә.
155—2—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 3 нче февральдә
РЕВИЗОР
Талон 91.
4 нче февральдә
МАСКАРАД
Талон 92.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
БҮГЕН ҺӘМ ҺӘР КӨН
Москва 4 нче труппасының
— соңгы гастрольләре —
ПОПУЛЯР КОМИК, ҺӘР ТӨРЛЕ ХАЙВАННАРНЫ ӨЙРӘТҮЧЕ,
РСФСР ның атказанган артисты орденлы
М. ЗОЛЛО үзенең антропозоологик — труппасы белән —
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында.
Телефоннар: 30—78 һәм 29—04.
Бүген, 3 нче февральдә
ЗУР КОНЦЕРТ
Катнашалар: оркестр, хор, балет, ТДАТ солистлары.
Талоннар белән кертелми.
Кич 9 сәгаттә башлана.

3 фазалы, беренче басымы 6.000 вольт, икенче басымы 220-380 вольт һәм 100 киловатт куәтле яңа
ТРАНСФОРМАТОРНЫ
икенче басымы 127-220 вольтлы шундый ук трансформаторга
АЛМАШАБЫЗ
Казан, Холодильник. Телефон 22—76.
154—2—2

Москвадан килгән инженерларны урнаштыру өчен, төрле срокларга
БҮЛМӘЛӘР КИРӘК
Түләү килешү буенча. Бауман урамы, 70. Телефон 44—05. Новицкий.
177—2—1

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН“ 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	БАЛТЫКЧЫЛАР
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	БӨЕК БҮЛӘК
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ДУСЛАР
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез ФЕДЬКА Кич ТРАКТОРЧЫЛАР Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (1 нче сериясе)
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ

„ЗАГОТЗЕРНО“ ның Казан базасы
Спартак урамындагы 42 нче йортка
(элек „Заготзерно“ ның Казан бүлеге урнашкан йортка)
КҮЧТЕ
Телефоннар: 33—95 һәм 27—19.
176—2—1

Татарстан АССР Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты Каменка санаторисенең урланган түгәрәк печатен гамәлдән чыккан дип санарга
173—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР, № А — 234 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 438.